ГЛАВА ИЛЯКСАЗСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
САРМАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САРМАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИЛЕКСАЗ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2 ноябрь 2020 ел № 4

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Илексаз авыл җирлегенең Игәнә-Баш авылы өлешендә 2021 елда гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Илексаз авыл җирлеге Уставының 18.1 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы, Сарман муниципаль районы, Игәнә-Баш авылы, Совет урамы, 16 а йорты адресы буенча урнашкан ФАП бинасында 2021 нче елның 13 ноябренә 13 сәгатьтә Сарман муниципаль районы Илексаз авыл җирлегенең Игәнә-Баш авылында гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләп кую.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: I нче группа инвалидлар, вакытлы хәрби хезмәт үтүче гражданнар, көндезге бүлекләрдә укучы студентлардан кала, Илексаз авыл җирлегендә теркәлгән 18 яше тулган һәр гражданга 2021 елда үзара салымны 300 сум күләмендә кертергә һәм шул акчаларны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итәргә тотарга Сез ризамы:

1) Игәнә-Баш авылы эчендәге юлларны ремонтлау (вак таш җәелгән чокырлар ремонтлау, вак таш ташу);

2) Игәнә-Баш авылында массакүләм чаралар (Сабантуй, юбилярлар, Җиңү көне, Өлкәннәр көне, Яңа ел) үткәрү өчен бүләкләр алу;

3) Игәнә-Баш авылында «Беларус 82.1 " тракторын карап тоту (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, һәм машина йөртүче хезмәте өчен түләү);

4) Игәнә-Баш авылында урамнарны яктырту объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (лампалар һәм яктырткычлар сатып алу һәм урнаштыру);

5) Игәнә-Баш авылы зираты өчен үзйөрешле газонокосилки сатып алу;

6) Игәнә-Баш авылы янгын сулыгын ремонтлау (килешү буенча);

7) Игәнә-Баш авылы өчен мотопомпа сатып алу.

«ӘЙЕ» «ЮК»

3. Әлеге карарны кабул ителгән көннән 7 көн эчендә Илексаз авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында, http://sarmanovo.tatarstan.ru хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга .

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Сарман муниципаль районы

Илексаз авыл җирлеге башлыгы: Гыйльфанов Ф. М.

МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ САРМАНОВСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ОГРН 1021601313183 Совет Илякзянского сельского поселения Илексаз авыл җирлеге Советы ИНН 1636001354